


Айсылу Мәхмvт кызы Семочкина, «Бердәм Россия» партиясенен Торбеево жирле бvлекчәсе секретаре, Мордовия Республикасы «Торбеево vзәк район хастаханәсе» баш табибы, Россия Президенты В.В.Путиннын Федераль Жыенга Юлламасын комментарияләде:

- Федераль Жыенга Юллама жәмгыять очен ин моһим мәсьәләләргә кагыла. Топ темалар - Россия халкын саклау һәм арттыру, аналар һәм балаларга, бигрәк тә тvбән керемле гаиләләргә ярдәм итv.

Россия Президенты В.В.Путиннын Федераль Жыенга Юлламасында, гадәттәгечә, сәламәтлек саклау проблемалары һәм әлеге кискен проблемаларны юкка чыгарачак чаралар билгеләп vтелде. Бу - кадрлар белән тәэмин итv дә, беренчел звенонын проблемалары да, медицина ярдәмен кvрсәтvнен сыйфаты һәм vз вакытында алу да.

Торбеево районында Президенты Юлламасында кvрсәтелгән чаралар vткәрелә инде.

2019 елнын икенче кварталыннан башлап Торбеево vзәк район хастаханәсе «Беренчел медик - санитар ярдәм кvрсәтvче медицина оешмасынын яна моделен булдыру» проектына керде. Олкәннәр һәм балалар регистратураларынын эше vзгәртелде, медицина хезмәтләрен максималь тиз һәм унайлы алу процессы оештырылды. Момкинлекләре чикләнгән пациентларга һәм балигъ булмаган балалары булган ата-аналарга аерым шартлар тудырылган. Хастаханәдә республика дәрәжәсендәге дәвалау оешмалары белән телемедицина консультацияләре кин кулланыла. Торбеево районынын алты фельдшер-акушерлык пункты Интернет челтәренә тоташтырылган, бу белгечләргә вакытында консультатив ярдәм алырга момкинлек бирә.

2019 елда Красноармейский поселогында модульле фельдшер-акушерлык пункты файдалануга тапшырылды. 2020 елда Куликово, Виндрей һәм Кажлодка авылларында тагын оч ФАПны эшләтеп жибәрv планлаштырыла. «Бердәм Россия» партиясенен Торбеево жирле бvлекчәсе Россия Федерациясе Президенты В.В. Путиннын Федераль Жыенга Юлламасында янгыраган башка инициативаларны да хуплый һәм аларны тормышка ашыру буенча актив эшләячәк, дип сойләде Айсылу Мәхмvт кызы Семочкина.

Наилә НАСЫРОВА